КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 21 май г.Казань № 718

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 20 июнь, 589 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 20 июнь, 589 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 12 декабрь, 1318 нче, 2023 ел, 26 апрель, 528 нче, 2024 ел, 3 апрель, 220 нче, 2025 ел, 01 февраль, 55 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми

мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

47 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

48 пунктта «айның 10 числосыннан да соңга калмыйча» сүзләрен «айның 10 нчы эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

53 пунктның беренче абзацында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин